| | |
|---|---|
| ГЛАВА АЗАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 ел , 30 октябрь. № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнарының 2026 елда узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 45-РТЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Азалак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Юлтимер авылы, Елга урамы, 5 йорты адресы буенча урнашкан Юлтимер авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне түбәндәгечә расларга: “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2026 елда 500 сум узара салым җыярга һәм күләмендә кертергә, шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотorга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- Юлтимер авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Юлтимер торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Юлтимер авылында Яңа, Тау, Яр буе,Үзәк, урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү).
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Юлтимер авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4. Санкциясез чүплекләрне бетерү:
- Юлтимер авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

“ӘЙЕ” “ЮК?”

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә Азалак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгүлүмәти стентларда урнаштырырга, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, https://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

РТ Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габдулгазизов